РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423586, г. Нижнекамск, пр. Строителей, 12
тел./факс (8555) 41-70-00

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

423586, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12
тел./факс (8555) 41-70-00

РЕШЕНИЕ

КАРАР

№ 47

2024 елның 27 ноябре

**Түбән Кама муниципаль районы Советының 2016 елның 11 ноябрендәге 62 номерлы карары белән расланган 2016-2021 елларга һәм 2030 елга кадәр план чорына Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының социаль-икътисадый үсеш Стратегиясенә үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законы, Түбән Кама муниципаль районы Советы нигезендә

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама муниципаль районы Советының 2016 елның 11 ноябрендәге 62 номерлы карары белән расланган 2016-2021 елларга һәм 2030 елга кадәрге план чорына Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының социаль-икътисадый үсеш стратегиясенә кертелә торган үзгәрешләрне расларга (кушымта).
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Уставы белән билгеләнгән тәртиптә рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны социаль-икътисадый үсеш, бюджет-финанс мәсьәләләре һәм муниципаль милек буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама муниципаль
районы Башлыгы

Р.Х. Муллин

Түбән Кама муниципаль районы Советының
2024 елның 27 ноябре
47 номерлы карарына
кушымта

Түбән Кама муниципаль районы Советының 2016 елның 11 ноябрендәге 62 номерлы карары белән расланган 2016-2021 елларга һәм 2030 елга кадәр план чорына Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының социаль-икътисадый үсеш стратегиясенә кертелә торган үзгәрешләр

Стратегиянең 4.1 бүлегенең 4.1 пунктындагы 4 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«4. Шәһәр паркы

Гамәлгә кертү - 2032 ел.

Максат: Түбән Кама шәһәренең җитештерү һәм торак объектлары арасында буфер яшел зона булдыру юлы белән халыкның экологик иминлеген һәм яшәү сыйфатын арттыру.

Объектларны 16:53:030103:23 кадастр номеры булган җир кишәрлеге чикләрендә урнаштыру планлаштырыла.

Әлеге проектны гамәлгә ашыру Түбән Кама шәһәре һәм Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетлары, Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, Түбән Кама муниципаль районы чикләрендә кадастр номерлары булган җир кишәрлекләрендә килештерелде

16:53:040601:133, 16:53:040601:1507, 16:53:040601:1510, 16:53:040601:1508, 16:30:011430:234, 16:30:011402:77, 16:53:030103:23, 16:30:000000:3902, 16:30:000000:3907, 16:30:011801:507, 16:30:011801:508, 16:30:011801:509, 16:30:011801:510, 16:30:011801:512, 16:30:011801:513, 16:30:011801:514, 16:30:011801:517, 16:30:011801:518, 16:30:011801:519, 16:30:011801:521, 16:30:011801:522, 16:30:011801:523, 16:30:011801:524, 16:30:011801:525, 16:30:011801:526, 16:30:011801:527.

«Этилен 600» индустриаль паркы объектларын кадастр номерлары булган җир кишәрлекләрендә урнаштыру өчен алына торган урман фонды җирләренең мәйданы

16:30:000000:3902, 16:30:000000:3907, 16:30:011801:507, 16:30:011801:508, 16:30:011801:509, 16:30:011801:510, 16:30:011801:512, 16:30:011801:513, 16:30:011801:514, 16:30:011801:517, 16:30:011801:518, 16:30:011801:519, 16:30:011801:521, 16:30:011801:522, 16:30:011801:523, 16:30:011801:524, 16:30:011801:525, 16:30:011801:526, 16:30:011801:527

785,5421 Га тәшкил итәчәк.

«Этилен 600» индустриаль паркының билгеләнгән чикләрдә урнашуына бәйле рәвештә 1.1-1.5 урман төзекләндерү документларына төзәтмәләр кертергә кирәк.

«Этилен 600» индустриаль паркы объектларын урнаштыру өчен тиешле муниципаль берәмлекләрне территориаль планлаштыру һәм шәһәр төзелешен зоналаштыру документларына үзгәрешләр кертергә.

Урман фонды җирләрен җирләрнең башка категорияләренә күчергәндә гамәлдәге урман законнары таләпләрен үтәү зарур. Россия Федерациясе Урман кодексының 04.12.2006 ел, № 200-ФЗ 62 маддәсендә урман торгызу киселгән, һәлак булган, зыян күргән

урманнарны торгызу, шулай ук урманнарның файдалы функцияләрен, аларның биологик төрлелеген - урман утыртмаларын кисүче затлар тарафыннан урман торгызу проекты нигезендә табигый, ясалма яки катнаш ысул белән саклау максатларында гамәлгә ашырыла дип каралган. Урманнарны торгызу кагыйдәләре, урманнарны торгызу проектының составы, урманнарны торгызу проектын эшләү һәм аңа үзгәрешләр кертү тәртибе Россия Табигать министрлыгының 04.12.2020 № 1014 боерыгы белән расланды.

Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге чиге буенча билгеләнгән «Түбән Кама» алдан билгеләнә торган социаль-икътисадый үсеш территориясе чикләрен үзгәртү проектын гамәлгә ашыру максатларында «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның с оставындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына тиешле үзгәрешләр кертүне тәэмин итәргә кирәк».

Түбән Кама муниципаль районы
Башлыгы урынбасары А.В. Умников